ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» апреля 2021 ел № 114

**Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 25 мартындагы 80 номерлы карары белән расланган «2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль норматив хокукый актны тәңгәлләштерүгә бәйле рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты арасындагы “Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына башка бюджетара трансферлар бирү турында” Килешү нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 25.03.2021 номерлы карары белән расланган «2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Программаның паспортында «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="4">Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары:</td><td colspan="3">Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан программаны финанслауның гомуми күләме:</td></tr>
<tr><td>ел</td><td>җирле бюджет</td><td>республика бюджеты</td></tr>
<tr><td>2021 ел</td><td>200 мең сум</td><td>122.5 мең сум (спортинвентарь);<br>331.4 (хоккей буенча программаларны тормышка ашыруга)</td></tr>
<tr><td>2022 ел</td><td>200 мең сум</td><td>124.5 мең сум (спортивный инвентарь);</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 350 мең сум.( хоккей буенча программаларны тормышка ашыруга) |
| | Барлыгы | 400 мең сум | 928.4 мең сум |

1.2 «2021-2022 елларга Әгерҗе муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү чаралары» 3 бүлегендәге «Матди-техник базаны үстерү» 5 бүлекчәсендәге 5.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № | Чаралар эчтәлеге | Башкару сроклары | Башкару өчен җаваплылар | Финанслау күләме (мең сум) | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | 2022 |
| 5.6 | Спорт мәктәпләрен җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендә бюджетара трансфертлар. (республика бюджеты) | 2021-2022 ел | МБУ «Спорт мәктәбе»; МБУ СОК «Олимп»» | 122.5 | - |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Карарның үтәлещен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе А.Э. Акбашев